## ТАУ / ГОРА

Тау - ул сихри көчкә, серләргә ия урын. Борын-борыннан алар кеше акылын һәм күңелен үзенең бөеклеге, мәгърурлеге, рухы белән җәлеп иткән. Ата-бабаларыбыз өчен ул изге урын булган, анда гашыйклар очрашкан, тугрылык вәгъдәләре, мәңгелек мәхәббәт антлары яңгыраган. Ләкин тормыш тегермәне кешеләрнең язмышын аяусыз иләи. Гореф-гадәтләр онытыла, вәгъдәләр мәгънәсен югалта, тау-матди табыш урынына әверелә. Шулай да табигать кануннары кешедән көчлерәк. Вакыт барын да үз урынына утырта. Кешеләрнең хыянәтен, ваемсызлыгын, комсызлыгын яраланган Тау гафу итәрме? Җир-ананың сыкравы язмышларда ничек чагылыр? Бу сорауларга җавап - ике гашыйк мәхәббәте тарихында.

Горы – это особое место. Испокон веков горы влекли людей своим величием, непоколебимостью, магической силой. Для наших предков гора была священным местом, где влюбленные произносили клятву верности друг другу. Но жернова жизни перемалывает судьбы людей так, что вековые традиции теряют свой сакральный смысл и обещания забываются. И тогда гора превращалась лишь в предмет наживы. Но в природе всё имеет обратную связь. Простит ли Гора, израненная алчностью людей, их предательство?
Как отзовется боль матушки–земли в их судьбах?
Об этом говорится в истории любви двух сердец.

## ЯШЬЛЕГЕҢ ИШЕК ШАКЫСА / ВСЕ ТОЛЬКО НАЧИНАЕТСЯ

Гомер үтеп бара, ә алда күпме мәшәкать: кызларны кияүгә бирергә (өчәү бит әле!), юбилейны уздырырга. Җитмәсә, тагын бер борчу - аның гомер иткән яраткан өстәлен яңага алыштырырга телиләр. Тик нәкъ шул яңа өстәл белән аларның тормышына бәхет тә ишек шакый.

Как сбросить с плеч десятки лет на пороге зрелого юбилея? Забыть про возраст и заняться собой? Это не про нашу героиню. Три дочери – невестки на выданье. Только вот с выгодной партией беда – запросы высокие. Пока заботливая мама решала насущный вопрос, судьба приготовила для нее самой неожиданный подарок! Ведь стать счастливой никогда не поздно!

## КИҢ УРАМНАР ТАР ИДЕ / ДЕРЕВЕНСКИЕ СТИЛЯГИ

Яшьлек кайчан да яшьлек инде ул! Чорына да карамый, милләтенә дә, иленә дә! Һәр буын аны сагына. Юкка гына «Эх, киң урамнар тар иде!» дип әйтмәгәннәрдер. Узган гасырның 60нчы еллары исә үзенең апрель җилләре белән тарихта да күңелдә дә эз салган. Күпме яңалык, күпме мөмкинлекләр ачыла, нинди чагу төсләргә манчыла шул чор яшьләренең тормышы! Джинсы, кеды, джаз, рок-н-ролл! Авылга шундый «мода» алып килгән шәһәр стилягалары урындагы яшьләр белән уртак тел табармы? Урамнар тар булмасмы?

Ох, как же манят всех воспоминания о молодости, пьянят, чаруют и вызывают чувство ностальгии. Да-да, вот то самое щемящее чувство ностальгии, в нашем спектакле и вернет нас в 60-е годы прошлого века: деревня, вечера на завалинке, песни под гармонь, звезды на чистом небе и первая любовь. А для пущей страсти - приехавшие из города новоиспеченные модные работники клуба. Ох и наведут они в деревне «шороху». Перемешается деревенская степенная культура с городской суетой и закружит всех в новых ритмах стиляг.

## КАР / СНЕГ

Төп вакыйга - геройларның җир тормышындагы хәлиткеч мизгелләреннән тупланган. Күңелдә тирән уелып калган хатирәләрдән. Аларга шатлыгы да, кайгысы да, авыр сынаулары да сыйган. Нинди нәтиҗәгә китерде ул аларны? Дөрес булганмы алар, әллә ялгышмы? Бу турыда уйланырга вакыт җитәрлек. Чөнки әсәрнең геройлары - фани дөнья белән бакыйлык арасындагы барзахта. Ике арадагы күпердә. Ничек үтәр алар ул араны? Нинди җавап тотар?

Наша жизнь – всего лишь миг космического времени. Но ответ придется держать всем. За все. К таким размышлениям призывает спектакль «Снег», где герои оказываются в лимбе. По мотивам священных писаний – это место пребывания душ, ожидающих назначения в вечном мире. Они встретились, чтобы помочь главному герою обрести святость души. Через те или иные ситуации. Порой не совсем радужные. А Снег - это лейтмотив не только чистоты, но и символ связи между небом и землей, между бренным и вечным.

## ТУТАШ / ТУТАШ. ПРЕРВАННЫЙ ПОЛЕТ...

Бу дөньяда һәр кешенең үз миссиясе бар. Кемдер балалар үстерә, кемдер йортлар төзи, кемдер шигырьләр яза. Әмма беренче тапкыр нәрсәдер эшләргә насыйп булганнарга нишләргә? Беренче булу — Сәхибҗамалның миссиясе шундый. Кыюлык һәм үз-үзеңә ышану! Менә нәрсә яшь Сәхибҗамалга уңышка ирешергә, беренче булырга, үзе артыннан ияртергә ярдәм итә. Романның героинясы Туташ - атаклы беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская үз үрнәгендә ничек нык һәм кыю булып калырга һәм авыр вакыт сынавы астында сынмаска икәнен күрсәтә.

На долю Сахибжамал выпала особая судьба - прорубить окно духовности и света в мир своих соотечественников. Миссия – стать первой. Легко ли было? Нет. Через тернии она шла к звездам – в 15 лет вышла на сцену. В 19 лет организовала свою театральную труппу. Блистала на многих сценах по всей России. Ее любили, ей рукоплескали! В пике ее славы в стране развязалась гражданская война. Оглушительный успех сменился забытьем. Смолкли бурные аплодисменты. Полет был прерван. Счастье творческого полета и драма земной жизни – все рядышком…

## МӘХӘББӘТ ЭЛМӘГЕ / УЗЕЛКИ ЛЮБВИ

Балконнан килеп кергән кунак - яшь, креатив заман кешесе. Ә фатир хуҗасы - бүгенге тормышта юллары буталган, шулай да искиткеч зур талант иясе. Бу очрашу аларның икесенең дә тормышын кискен үзгәртә: уртак бизнес, дан-мал, табыш-алкыш! Ә иң мөһиме - яшь егет гомер юлы үткән ир узаманына дүрт хатыны арасында кайсысы чынлап та үзенә тиң яр икәнлеген аңларга ярдәм итә.

Невероятный случай, произошедший в квартире известного писателя, перевернул всю его жизнь. Благодаря нежданному гостю с балкона, унылый мир вокруг него изменился и приобрел другие краски.
А главное мнимые узелки любви быстро развязались. А настоящая любовь, выдержавшая испытание, завязалась в крепкий семейный союз.

## 41-нең КӨЗЕНДӘ / ОСЕНЬЮ 41-го

Төп геройларның хатирәләре безне сугышның иң дәһшәтле көннәренә - 1941-нең көзенә алып кайта. Шундагы беренче яу аларның күңелендә мәңгелеккә уелып кала. Сугыш тәмамлангач та тынгылык бирми ул. Күптән тыныч тормышта яшәгән, инде оныклар үстергән фронтовиклар бер-берсен табып очрашырга ниятли. Язмыш юллары төрлечә була аларның. Тик нинди генә сынаулар алдында калмасын җиңүчеләр буыны намусын, кешелек сыйфатларын, мәрхәмәтлеген югалтмый.

Сюжет переплетает сегодняшние дни с первым боем героев в роковом 41-ом. Несмотря на то, что далее их пути разошлись, эта встреча осталась в сердцах на всю жизнь. Уже в мирные дни фронтовики нашли друг друга. Перед какими бы испытаниями они не оставались, поколение победителей сумело сохранить истинные человеческие качества и любовь к Родине.

## ҖӘЯҮЛЕ МӘХМҮТ / ПЕШИЙ МАХМУТ

О, мәхәббәт! Азмы язмышларны
Дөнья тәмугында яндырдың.
Азмы исемнәрне, күккә язып,
Мәңгелек җыр итеп калдырдың.
Мәхәббәт турында күпме язылган, үлемсез легендалар теркәлгән. Күпме гашыйклар шушы югары хис өчен җанын кыйган. Тик шулай да һәр йөрәк аны яңадан үзенчә үтәргә тели, мәхәббәте белән бәхетле булырга омтыла. Әмма илаһи да, татлы да хис – аяусыз көч шул. Ул ләззәт кенә түгел, газап та китерергә сәләтле, күкләргә чөеп, аяусыз рәвештә җиргә бәрергә дә. Мәдинәсенә мәңгелек гашыйк Мәхмүт тә сөю Акбузатын иярли алмый, һаман шулай җәяү атлый да атлый...

Сколько судеб безжалостно скомкала,
Сколько жизней ты оборвала,
Скольким смертным, став вечными строками,
О любовь, ты бессмертье дала!
Через эти строки Мустай Карим, воспевший оду самой из прекрасных и могущественных чувств, коим одарила нас природа, раскрывает всю ее противоречивость и многогранность. Она способна, как окрылять, возвышать человека, сделать его счастливым, так и причинять боль, горькие разочарования. Однако только любовь придаёт жизни смысл и делает ее настоящей. Герои спектакля, проживая свою историю любви, познают всю полноту ее природы.